# ЧИШМӘ БАШЫ




Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
«МӨНДЕШ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ» МБМББУ,
гыйнвар, 2026 ел № 13

***Ата-аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы***

***Газетаның сәхифәләре:***

*1. Курчак театры - сабыйлар шатлыгы*
*2. «Без – Тукайлы халык» районкүләм бәйге җиңүчеләре билгеле*
*3. Әкият илендә кунакта*
*4. Уйный-уйный үсәбез*
*5. Иске Яңа елны каршылап*

**Баш мөхәррир:**
**балалар бакчасы мөдире**
**Мостафина Р.Г.**
**Мөхәррир урынбасарлары:**
**музыка җитәкчесе Хөсәенова Г.Ф.**
**тәрбиячеләр: Хөсәенова Р.Р.,**
**Җәләлиева А.Г., Шәкүрова Р.С.,**
**Хөсәенова В.В.**

## *Курчак театры балаларга зур шатлык кына түгел, эстетик тәрбия дә бирә сөйләмне үстерә, тирә-юньне аңларга өйрәтә.*

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар курчак театры спектакльләрен карарга бик яраталар.Ул аларга якын, аңлаешлы. Балалар таныш һәм яраткан хәрәкәтләнүче һәм сөйләшүче, кызык курчакларын: аю, куян, песи, этне һ.б. күрәләр. Ләкин курчак театрына күңел ачу чарасы итеп кенә карарга кирәкми. Аның тәрбияви мәгънәсе бик мөһим. Мәктәпкәчә яшьтә баланың тирә-юньгә мәхәббәте, характеры, кызыксынуы формалаша башлый. Нәкъ шушы яшьтә балаларга дуслык, яхшылык, дөреслек, хезмәт сөючәнлек мисалларын күрсәтү файдалы. Кечкенәләр төркемендә без еш кына курчак театры уйныйбыз.







## Без – Тукайлы халык»
## районкүләм яшь иҗатчылар
## бәйгесе җиңүчеләре билгеле.

2026 елда бөек шагыйребез Г.Тукайның тууына 140 ел тулу уңаеннан Арча муниципаль районы Г.Тукай исемендәге Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбе базасында «Без – Тукайлы халык» исемле иҗади эшләр конкурсы оештырылды.

Безнең бакчабызда тәрбияләнүче балалар әти-әниләре белән берлектә «Тукай геройлары безнең белән» дип исемләнгән декоратив-гамәли сәнгать эшләнмәләре ясап алып килделәр. Барлык эшләнмәләр арасыннан 5 эшне сайлап Яңа Кырлай мәктәбенә конкурска җибәрдек. Бу эшләр барысы да җиңүче дипломына лаек булдылар.

***Юзаева С.Д – «Шүрәле» әкиятенә, Лотфуллин С.С. – «Шаян песи» шигыренә, Хисматуллина З.И. «Кисекбаш» шигыренә, Хөсәйнова М.Р. – «Кызыклы шәкерт» шигыренә, Сафаргалиев Ә.А. – «Сөткә төшкән тычкан» шигыренә эшләнмәләр ясадылар.***

Барлык катнашкан әти-әниләргә рәхмәтебезне белдерәбез.








## *Әкият илендә кунакта*

Балалар бакчасында сабыйларның иң яраткан шөгыльләренең берсе, ул, әлбәттә, әкият тыңлау. Әкият аша алар игелекле, ярдәмчел, хезмәт сөючән булырга өйрәнәләр. Барлык әкиятләрдән дә артыграк балалар Г.Тукай, А.Алиш әкиятләрен яраталар. Шуны истә тотып, без алар белән эшчәнлек вакытында һәм режим моментларында әкиятләр укыйбыз, соңыннан укылган әкият буенча әңгәмә корабыз.

Быелгы ел исә Татарстаныбызда Г.Тукайның тууына 140 елга багышланачак. Шуны истә тотып, бакчабызда Г.Тукай иҗаты аерым урын алачак.













## Безнең балалар бакчасында тәрбиячеләр балалар белән төрле кызыклы, хәрәкәтчән уеннар уйнарга яраталар.

## Аеруча тупны үз итәләр кечкенәләр.

**«Тупны тәгәрәтә бел!»** уенында балаларны ярымтүгәрәккә аякларын сузып утырталар. Тәрбияче аларга каршы утырып, кечкенә резина тупны (тупның диаметры 20-25см булса әйбәт) чират белән һәрбер баланың каршысына тәгәрәтә, ә балалар тупны кире тәрбиячегә каршы тәгәрәтәләр.

Туп белән уйнау бала күңеленә һәрвакыт хуш килә.Һәр очрашуда балалар рәхәтләнеп уйныйлар, бакча мохите белән танышалар. Шул рәвешчә, баланы алдан ук балалар бакчасына әзерләү бара. Әлбәттә, мондый шөгыльләр нәни бала күнелендә балалар бакчасы турында уңай тәэсирләр калдыра дип шикләнмичә әйтә алабыз.









Озакка сузылган гыйнвар бәйрәмнәреннән соң балалар бакчасына килүгә сабыйлар белән шау-гөр килеп Иске Яңа ел бәйрәмен уздырдык. Кыш бабай белән Кар кызы да безгә кабат кунакка килделәр.

Бергәләшеп җырладык, биедек, чыршы тирәли әйләндек, кызыклы уеннар уйнадык. Бәйрәм ахырында яшел чыршыбыз белән киләсе елга кадәр саубуллашып, һәрберебез теләкләр теләдек.

2026 нчы ел безнең балалар бакчасы өчен тыныч, уңышлы, нәтиҗәле ел булсын иде!








